| ГЛАВА СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КАМЫШЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | Урта Камышлы ав. | КАРАР |
|---|---|---|

«3» ноябрь 2021 ел № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 16 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Кече Камышлы авылы, К.Маркс урамы, 32нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Декабристлар урамындагы 1-38нче йортларда, К.Маркс тыкрыгы 1нче йортта яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2021 елның 16 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Кече Камышлы авылы, К.Маркс урамы, 32нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча К. Маркс урамындагы 1-67нче йортларда яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Кече Камышлы авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. «Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- Кышын юлларны кардан чистарту өчен тагылмалы җайланма сатып алу
- Урта Камышлы торак пунктында җирлек әһәмиятендәге юлларны ремонтлау.
- Зиратларның коймасын төзекләндерү һәм карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы В.П. Вафина